| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ<br>ВВЕДЕНСКО-СЛОБОДСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЮГАРЫ ОСЛАН<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ<br>ВВЕДЕНСКИЙ БИСТӘСЕ<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |
| РЕШЕНИЕ | | КАРАР |

с. Введенская Слобода

29.09.2017  №37-161

Введенский Бистәсе авыл җирлеге территориясендә гражданнарның  үзара салым акчалары кертелү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләү турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокуклары һәм референдумда катнашу хокукының нигез гарантияләре» 12.06.2002 № 67-ФЗ Федераль законның 15 статьясына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 №131-ФЗ Федераль законның 22, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 20 статьясындагы 1 пунктына ярашлы рәвештә, Введенский Бистәсе авыл җирлеге Уставының 11 ст., Введенский Бистәсе авыл җирлеге Советының «Җирле референдум үткәрү инициативасы турында» 20.09.2017 №36-158 карары, Введенский Бистәсе авыл җирлеге башлыгының «Җирле референдум үткәрү инициативасы турында»20.09.2017 №3 карары нигезендә,

Югары Ослан муниципаль районы

Введенский Бистәсе авыл җирлеге Советы

карар итте:

1.2017 елның 19 ноябренә Введенский Бистәсе  авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган сорауны түбәндәгечә расларга:

«Сез 2018 елда Введенский Бистәсе авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә

һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы:

- Введенский Бистәсе һәм Савино авылында урнашкан зиратларны төзекләндерү

"ӘЙЕ" "ЮК".

3. Әлеге карарны «Волжская новь» район газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Введенский Бистәсе авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында урнаштырырга.

4. Әлеге карар аның рәсми бастырып чыккан көненнән үз көченә керә.

Совет рәисе,

Югары Ослан муниципаль районы

Введенский Бистәсе авыл җирлеге башлыгы Д.В. Морозов